РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 19 ноябре Кукмара ш. № 90

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кушып бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроле турында Нигезләмә;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының

рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроле турынд НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – муниципаль контроль).

1.2. Муниципаль контроль предметы булып юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм физик затларның (алга таба – контроль үткәрелә торган затлар) мәҗбүри таләпләрне үтәве тора:

1) автомобиль юлларына карата билгеләнгән, автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге өлкәсендә:

а) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларында һәм (яки) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә карата;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм аларда ясалма юл корылмаларын (юл-төзелеш материалларына һәм эшләнмәләренә таләпләрне дә кертеп) капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен гамәлгә ашыруга карата;

2) автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында даими пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына керми торган даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүгә карата билгеләнгән;

Муниципаль контроль предметы булып, шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше тора.

1.3. Муниципаль контроль объектлары (алга таба – контроль объекты) булып түбәндәгеләр тора:

1.3.1. контроль үткәрелә торган затларның, кысаларында мәҗбүри, шул исәптән эшчәнлекләрен, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлгә ашыручы контроль үткәрелә торган затларга карата куела торган таләпләр үтәлергә тиешле автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмаулары);

1.3.2. контроль үткәрелә торган затларның эшчәнлеге, шул исәптән мәҗбүри таләпләр куела торган эш һәм хезмәт күрсәтүләренең нәтиҗәләре;

1.3.3. контроль үткәрелә торган затлар ия булган һәм (яисә) файдалана торган аларга карата мәҗбүри таләпләр куела торган биналар, корылмалар, төзелмәләр, территорияләр, җир кишәрлекләрен, предметларны һәм башка объектларны да кертеп.

1.4. Контроль объектларын исәпкә алу түбәндәгеләрне булдыру юлы белән башкарыла:

контроль чараларның бердәм реестры;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән башка дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системалары.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 248-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясындагы 2 өлеше һәм 17 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Контроль орган тарафыннан, мәгълүмат системасын кулланып, контроль объектларын исәпкә алу алып барыла.

1.5. Муниципаль контроль Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Контроль органы) тарафыннан башкарыла.

1.6. Контроль органы исеменнән муниципаль контрольне түбәндәге вазыйфаи затлар башкарырга хокуклы:

1) Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары);

2) вазыйфаи бурычларына әлеге Нигезләмә, вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи инструкция нигезендә муниципаль контроль төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү (алга таба – инспектор) кергән Контроль органының вазыйфаи заты.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле контроль органының вазыйфаи затлары исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән.

Контроль органының контроль чарасын үткәрү турында Карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары булып тикшерү органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары (алга таба – контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затлары) тора.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, профилактик чаралар, контроль чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезләмәләре кулланыла.

## 2. Зыян (югалту) китерү куркынычы (риск) категорияләре

2.1. Муниципаль контроле профилактик чараларны һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларны эчтәлеген (шул исәптән тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрнең күләме), интенсивлыкны һәм нәтиҗәләрне билгели торган зыян (югалту) китерү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла шул ук вакытта зыян (югалту) китерү куркынычын бәяләү һәм идарә итү өчен файдаланыла торган белешмәләргә Контроль орган тарафыннан даими нигездә мониторинг (җыю, эшкәртү, анализ һәм исәпкә алу) үткәрелә.

2.2. Зыян (югалту) китерү куркынычы белән идарә итү максатларында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль объектлары зыян (югалту) китерү куркынычы булган түбәндәге категорияләрнең берсенә кергә мөмкин (алга таба – куркыныч категорияләре):

шактый зур куркыныч (значительный риск);

урта куркыныч (средний риск);

уртача куркыныч (умеренный риск);

түбән куркыныч (низкий риск).

2.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү критерийлары әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы белән билгеләнгән.

2.4. Контроль объектын рискның бер категориясенә кертү аның характеристикаларын расланган риск критерийлары белән чагыштыру нигезендә Контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы булып контроль объекты параметрларына туры килү яки тайпылу тора, алар үзләре мәҗбүри таләпләрне бозу булмыйлар, ләкин әмма мондый хокук бозулар һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы булу турында югары ихтималлылык дәрәҗәсе белән раслыйлар.

2.5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге Совет карары белән раслана.

2.6. Контроль объекты билгеле бер куркыныч категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

2.7. Контроль органы объектның куркынычның бүтән категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркыныч критерийларын үзгәртү турында белешмәләр кергән көннән биш эш көне эчендә контроль объектының куркыныч категориясен үзгәртү турында Карар кабул итә.

## Муниципаль контрольне тормышка ашырганда үткәрелә торган профилактик чараларның төрләре

Муниципаль контрольне тормышка ашырганда, Контроль органы түбәндәге төр профилактик чаралар үткәрә:

1) мәгълүмат бирү;

2) хокук куллану практикасын гомумиләштерү;

3) кисәтү белдерү;

4) консультация бирү;

5) профилактик визит.

Профилактик чаралар ел саен Контроль органы тарафыннан раслана торган закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычын профилактикалау Программасы нигезендә гамәлгә ашырыла. Шулай ук әлеге Программада каралмаган профилактик чаралар үткәрелергә мөмкин.

### 3.1. Мәҗбүри таләпләрне үтәү һәм хокук куллану практикасын гомумиләштерү мәсьәләләре буенча контроль үткәрелә торган һәм башка кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1.1. Контроль орган контроль үткәрелә торган һәм башка кызыксынган затларга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән, контроль үткәрелә торган затларның дәүләт мәгълүмат системаларында шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башка формаларда мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерүне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны җайга салучы норматив хокукый актлар текстлары;

2) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр турында, аларның үз көченә керү вакытлары һәм тәртибе турында белешмәләр;

3) аларның үтәлешен бәяләү контроль предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган әлеге актларның структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар исемлеге, шулай ук гамәлдәге редакциядәге текстлар белән мәҗбүри таләпләрне бозганда кулланыла торган җаваплылык чаралары турында мәгълүмат;

4) үз-үзеңне тикшерү өчен аларны куллануны рөхсәт итә торган форматта расланган тикшерү кәгазьләре;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча кулланмалар;

6) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы (риск) индикаторлары исемлеге, контроль объектларын куркыныч (риск) категорияләренә кертү тәртибе;

7) куркыныч категориясен күрсәтеп, ел саен контроль чаралар планын формалаштыру кысаларында исәпкә алына торган контроль объектлары исемлеге;

8) зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасы һәм контроль органы тарафыннан планлы тикшерү чаралары үткәрү планы (мондый чаралар үткәргәндә);

9) контроль органы тарафыннан контроль үткәрелә торган заттан соратып алына торган белешмәләрнең тулы исемлеге;

10) мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча консультацияләр алу ысуллары турында белешмәләр;

11) контроль органы тарафыннан контроль үткәрелә торган затларның намуслылыгын стимуллаштыру чараларын куллану турында белешмәләр;

12) контроль органының хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладлар;

13) муниципаль контроль турында докладлар;

14) үз-үзеңне тикшерү (булганда) ысуллары һәм процедурасы турында мәгълүмат, шул исәптән үз-үзеңне тикшерү уздыру һәм мәҗбүри таләпләрне үтәү декларациясен әзерләү буенча методик тәкъдимнәр, һәм контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан бирелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү декларацияләре турында мәгълүмат;

15) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда һәм (яисә) зыян китерү куркынычларын профилактикалау программаларында каралган башка белешмәләр.

Контроль органы әлеге мәгълүматларны актуаль хәлдә тотарга тиеш.

## 3.2. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү

3.2.1. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль орган тарафыннан елга 1 тапкыр үткәрелә һәм түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1) Контроль орган һәм аның вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль контроль турында мәҗбүри таләпләрне, Россия Федерациясе законнарын куллануга бердәй якын килүне тәэмин итү;

2) күрсәтелгән бозулар барлыкка килүгә ярдәм итә торган мәҗбүри таләпләрне, сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны типик бозуларны ачыклау;

3) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү очракларын анализлау, зыян (югалту) китерүнең чыганакларын һәм куркыныч факторларын ачыклау;

4) мәҗбүри таләпләрне актуальләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

5) дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү.

3.2.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның хокук куллану практикасын гомумиләштерү үткәрелгән контроль чаралары һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматларны җыю һәм анализлау ярдәмендә Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2.3 Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча, Контроль органы хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерли.

3.2.4 Хокук куллану практикасы турында доклад Контроль органы җитәкчесе тарафыннан муниципаль берәмлек уставы нигезендә чыгарыла торган күрсәтмә белән раслана һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы официаль сайтында хисап елыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

### 3.3. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү

3.3.1. Әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозу яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр булган очракта, һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китергәне яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы тудырганы турында расланган мәгълүматлар булмаганда, Контроль органы контроль үткәрелә торган затка мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү (алга таба – кисәтү) игълан итә һәм мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә.

3.3.2. Кисәтү Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик формалары турында» боерыгы белән расланган форма буенча төзелә.

3.3.3. Контроль үткәрелә торган зат кисәтү алган көннән соң ун эш көне эчендә Контроль органга кисәтүгә карата кире кагу (возражение) бирергә хокуклы.

3.3.4. Кире кагуда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) каршылык җибәрелә торган Контроль органы атамасы;

2) юридик затның атамасы, шәхси эшмәкәр яки гражданинның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булганда), шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), контроль үткәрелә торган затка җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) кисәтү датасы һәм номеры;

4) контроль үткәрелә торган затның игълан ителгән кисәтүләр белән килешмәвенә дәлилләр;

5) контроль үткәрелә торган затның кисәтү алу датасы;

6) шәхси имза һәм дата.

7) салым түләүченең – юридик затның, шәхси эшмәкәрнең идентификация номеры;

8) паспортның яки шәхесне раслаучы башка документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны (гражданнар өчен);

3.3.5. Контроль органга карата каршылыклар 248-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән очракларда контроль үткәрелә торган зат тарафыннан кәгазьдә почта аша яки гади электрон имза яки көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Контроль органының кисәтүдә күрсәтелгән электрон почта адресына яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән җибәрелә.

3.3.6. Контроль үткәрелә торган зат, кирәк булган очракта, үз дәлилләрен раслап, каршылыкка тиешле документлар яки аларның расланган күчермәләрен терки.

3.3.7. Контроль органы кисәтүгә карата каршылыкны аны алганнан соң унбиш эш көне эчендә карый.

3.3.8. Каршылыкны карау нәтиҗәләре буенча Контроль органы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кисәтүне гамәлдән чыгару формасында каршылыкны канәгатьләндерә;

2) баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, каршылыкны канәгатьләндерүдән баш тарта.

3.3.9. Контроль органы контроль үткәрелә торган затка каршылыкны карап тикшерү нәтиҗәләре турында кисәтүгә карата каршылыкны караганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

3.3.10. Каршылыкны шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

3.3.11. Контроль органы мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында үзе игълан иткән кисәтүләрне исәпкә ала һәм, башка профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү өчен, тиешле мәгълүматларны куллана.

## 3.4. Консультация бирү

3.4.1. Контроль үткәрелә торган затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча башкарыла:

1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;

2) контроль чаралар үткәрү вакыты (периодичность);

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итү тәртибе;

4) Контроль органы карарларына шикаять бирү тәртибе.

3.4.2. Инспекторлар контроль үткәрелә торган затларга һәм аларның вәкилләренә түбәндәгечә консультацияләр бирә:

1) телефонан телдән аңлатмалар рәвешендә, видео-конференц-элемтә аша, шәхсән кабул итү вакытында яисә профилактик чара, контроль чара уздыру барышында;

2) рәсми сайтта контроль үткәрелә торган затлар һәм аларның вәкилләренең бер типтагы мөрәҗәгатьләре (10 нан артык бер типтагы мөрәҗәгать) буенча Контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты кул куйган язмача аңлатмалар урнаштыру юлы белән.

3.4.3. Инспекторлар тарафыннан һәр гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә шәхси консультацияләр бирү 10 минуттан артмаска тиеш.

Телефоннан сөйләшү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

3.4.4. Контроль органы контроль үткәрелә торган затларга һәм аларның вәкилләренә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирми.

3.4.5. Язма рәвештә консультация бирү Контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан түбәндәге очракларда башкарыла:

а) контроль үткәрелә торган зат тарафыннан консультация мәсьәләләре буенча язмача җавап бирү турында язмача сорату бирлегән;

б) куелган сорауларга консультацияләр бирү вакытында җавап бирү мөмкин түгел;

в) куелган сорауларга җавап бирү өстәмә мәгълүмат соратып алуны таләп итә.

3.4.6. Контроль үткәрелә торган зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларда язмача җавап бирү турында запрос җибәрергә хокуклы.

---

[1]

3.4.7. Контроль органы үткәрелгән консультацияләр исәбен алып бара.

3.5. Профилактик визит

3.5.1. Профилактик визит контроль үткәрелә торган затның эшчәнлек алып бару урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән инспектор тарафыннан үткәрелә.

Профилактик визитның дәвамлылыгы эш көне дәвамында ике сәгатьтән дә артмый.

3.5.2. Инспектор түбәндәгеләргә карата мәҗбүри профилактик визит үткәрә:

1) автомобиль транспорты һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга керешүче контроль үткәрелә торган затларга карата мондый эшчәнлек башланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча (эшчәнлек башлану турында мәгълүмат булганда);

2) шактый зур куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата контроль объектын әлеге категориягә кертү турында Карар кабул ителгән көннән бер елдан да соңга калмыйча.

3.5.3. Профилактик визитлар контроль үткәрелә торган затлар белән килешенеп үткәрелә.

3.5.4. Контроль органы контроль үткәрелә торган затка профилактика визитын үткәрү турында аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр җибәрә.

Контроль үткәрелә торган зат, бу хакта Контроль органына аны үткәрү датасына кадәр кимендә өч эш көне алдан хәбәр итеп, профилактик визит (мәҗбүри профилактик визитны да кертеп) уздырудан баш тартырга хокуклы.

3.5.5. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә язма рәвештә яисә электрон документ формасында төзелә һәм түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

1) хәбәрнамәне төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Контроль органы исеме;

3) контроль үткәрелә торган затның тулы исеме;

4) вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

5) мәҗбүри профилактик визитның датасы, вакыты һәм урыны;

6) вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә контроль үткәрелә торган зат адресына язмача яки электрон документ формасында җибәрелә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү вакыты контроль органы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

3.5.6. Профилактик визит нәтиҗәләре буенча инспектор профилактик визит үткәрү турында акт төзи.

3.5.7. Контроль орган үткәрелгән профилактик визитларның исәбен алып бара.

**4. Муниципаль контроль кысаларында үткәрелә торган контроль чаралар**

4.1. Контроль чаралар Гомуми сораулар

4.1.1. Муниципаль контроль түбәндәге планлы һәм планнан тыш тикшерү чараларын үткәрүне оештыру юлы белән Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла:[2]

инспекция визиты, рейд тикшерүе, документар тикшерү, күчмә тикшерү – контроль үткәрелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлек иткәндә;

мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшерү – контроль үткәрелә торган затлар белән үзара бәйләнешсез.

4.1.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль үткәрелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлек итү булып түбәндәгеләр тора:

инспектор һәм контроль үткәрелә торган зат яки аның вәкиле арасында очрашулар, телефоннан һәм башка сөйләшүләр (турыдан-туры хезмәттәшлек);

документлар, башка материаллар соратып алу;

инспекторның контроль үткәрелә торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында булуы (инспекторның һәркемгә ачык булган җитештерү объектларында булу очракларыннан тыш).

4.1.3. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә башкарыла торган контроль чаралар Контроль органы тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча үткәрелә:

1) Контроль органында зыян (югалту) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы йә контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү сроклары җитү;

3) Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контроль үткәрелә торган затларга карата контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Контроль органы карарын үтәү срогы тәмамлану – Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда.

Контроль органы вәкаләтле вазыйфаи затларының биремнәре нигезендә, Контроль органының эш планнарында булган биремнәрне дә кертеп, инспекторлар тарафыннан үзара бәйләнешсез контроль чаралар, шул исәптән, Федераль закон белән билгеләнгән очракларда үткәрелә.

4.1.4. Планлы һәм планнан тыш контроль чаралары, контроль үткәрелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлек итмичә үткәрелә торган чаралардан тыш, инспектор һәм тикшерү чарасын үткәрүгә җәлеп ителә торган затлар тарафыннан түбәндәге контроль гамәлләрне башкару юлы белән үткәрелә:

2

карау;

сораштыру;

язмача аңлатмалар алу;

документлар таләп итү;

экспертиза.

4.1.5. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чараны, шулай ук документар тикшерү үткәрү өчен, Контроль органның вәкаләтле заты кул куйган, түбәндәге белешмәләр күрсәтелгән Контроль органының карары кабул ителә:

1) карар кабул итү датасы, вакыты һәм урыны;

2) карар кем тарафыннан кабул ителгән;

3) контроль чарасын үткәрү нигезләре;

4) контроль төре;

5) инспекторның (инспекторларның, шул исәптән инспекторлар төркеме җитәкчесенең), контроль чараны үткәрүгә вәкаләтле, шулай ук контроль чараны үткәрүгә җәлеп ителә торган белгечләрнең, экспертларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булган очракта) яки мондый чараны үткәрүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмасының исеме;

6) контроль чара үткәрелә торган контроль объекты;

7) контрольүткәрелә торган зат тарафыннан эшчәнлек алып бару урыны адресы яисә контроль чарасы үткәрелә торган башка контроль объектларының урнашу адресы рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин;

8) контроль чарасы уздырыла торган контроль объектының мәҗбүри таләпләргә туры килүе өчен җаваплы гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса) яисә оешманың исеме, оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) адресы рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин;

9) контроль чарасының төре;

10) контроль чара кысаларында башкарыла торган контроль гамәлләр исемлеге;

11) контроль чарасы предметы;

12) әгәр аларны куллану мәҗбүри булса, тикшерү кзгазьләре;

13) контроль чарасын үткәрү датасы, шул исәптән контроль үткәрелә торган зат белән турыдан-туры хезмәттәшлек вакыты (контроль үткәрелә торган зат белән турыдан-туры хезмәттәшлек срогы өлешендә рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин);

14) мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү өчен кирәк булган граждан, оешма тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге (тикшерү чарасы кысаларында контроль үткәрелә торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү максатларында документлар бирү каралган очракта);

15) әгәр контроль төре турында нигезләмәдә каралган булса, башка белешмәләр.

Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне, күчмә тикшерүне үткәрүгә карата әлеге контроль чарасын үткәрү турында нигезләмәнең әлеге пунктының беренче абзацында каралган карар кабул итү таләп ителми.

4.1.6. Контроль чаралар контроль органның контроль чараларын үткәрү турындагы карарында күрсәтелгән инспекторлар тарафыннан үткәрелә.

Кирәк булганда, Контроль органы контроль чараларын үткәрүгә экспертларны, билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән эксперт оешмаларын һәм реестрга кертелгән, контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны, эксперт оешмаларны җәлеп итә.

4.1.7. Контроль үткәрелә торган зат белән хезмәттәшлекне күз алдында тота торган контроль чарасы тәмамланганнан соң, инспектор Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча контроль чарасы актын (алга таба шулай ук – акт) төзи.

Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нәкъ менә нинди мәҗбүри таләп бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә.

Ачыкланган бозуларны контроль үткәрелә торган зат белән хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль чара тәмамланганчы бетергән очракта, актта аны бетерү факты күрсәтелә.

4.1.8. Мәҗбүри таләпләрне бозуга дәлил булган документлар, башка материаллар актка теркәлә.

Контроль чараларын үткәргәндә тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлергә тиеш.

4.1.9. Актны рәсмиләштерү, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урынында башкарыла.

4.1.10. Дәүләт, коммерция, хезмәт яки закон тарафыннан саклана торган башка сердән торган мәгълүматны эченә алган контроль чара нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

4.1.11. Контроль чарасы актында бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контроль үткәрелә торган зат әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә каралган тәртиптә шикаять җибәрергә хокуклы.

## 4.2. Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча контроль орган тарафыннан күрелә торган чаралар

4.2.1. Контроль органы, контроль чарасы үткәргәндә контроль үткәрелә торган зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланганда, түбәндәгеләрне башкарырга бурычлы:

1) саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүне булдырмау яисә аны китерүне туктату буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә, тикшерү барышында контроль объектына ия булган һәм (яки) аннан файдаланучы граждан, оешманың эшчәнлеге, аларның биналар, төзелмәләр, корылмалар, помещениеләр, җиһазлар, транспорт чаралары һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләве (кулланууы), алар тарафыннан җитештерелә торган һәм сатыла торган товарлар, башкарыла торган эшләр,

күрсәтелә торган хезмәтләр закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры зыян (югалту) китерү куркынычын тудыруы яисә мондый зыян (югалту) китерелгәнлеге ачыкланган очракларда, хәтта биналар, төзелмәләр, корылмалар, помещениеләр, җиһазлар, транспорт чаралары һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләүне (куллануны) тыю турында һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы янау һәм аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди үтемле ысул белән гражданнарга, оешмаларга мәгълүмат җиткерү хакында таләп белән хәтта судка мөрәҗәгать итү дә булырга мөмкин.

2) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүне булдырмау буенча чаралар күрергә;

3) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча рекомендация бирү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлтелгән башка чаралар үткәрү турында мәсьәләне карарга.

4.2.2. Контроль үткәрелә торган зат тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә кабул ителгән карарның үтәлү срогы чыккач яисә, күрсәтелгән вакыт чыкканчы, контроль үткәрелә торган зат әлеге карар белән бирелергә тиешлеге билгеләнгән документларны һәм белешмәләрне тапшырганда, яисә йә мәҗбүри таләпләрне үтәүне күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында мәгълүмат алу очрагында, Контроль органы карарның үтәлешен тәкъдим ителгән документлар һәм белешмәләр, алынган мәгълүмат нигезендә бәяли.

4.2.3. Күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр контроль үткәрелә торган зат тарафыннан тапшырылмаса, яки алар нигезендә йә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин түгел икән, Контроль органы әлеге карарның үтәлешен инспекция визиты, рейд тикшерүе яки документар тикшерү юлы белән бәяли.

Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның үтәлешенә бәя бирелгән очракта, күчмә тикшерү үткәрергә рөхсәт ителә.

4.2.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.2.3 пунктында каралган контроль чараны үткәрү нәтиҗәләре буенча Контроль органы карарның үтәлмәвен яки тиешенчә үтәлмәвен ачыкласа, ул әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 1 пунктчасында каралган карарны, аны үтәүнең яңа срокларын күрсәтеп, янә контроль үткәрелә торган затка тапшыра.

Контроль органы карарының үтәлеше турындагы мәгълүмат тулы күләмдә контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына кертелә.

### 4.3. Планлы тикшерү чаралары

4.3.1. Планлы контроль чаралар чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрүнең Контроль органы тарафыннан төзелә торган һәм прокуратура

органнары белән килештерелергә тиешле планы (алга таба – еллык чаралар планы) нигезендә үткәрелә.

4.3.2. Куркынычның аерым категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата планлы контроль чаралары үткәрү төрләре, кабатлану вакыты зыян (югалту) китерү куркынычына карап билгеләнә.

4.3.3. Контроль органы планлы тикшерү чараларының түбәндәге төрләрен үткәрергә мөмкин:

инспекция визиты;

рейд тикшерүе;

документар тикшерү;

г) күчмә (урынга барып) тикшерү.

Югары риск категориясенә керә торган объектларга карата инспекция визиты үткәрелә.

Урта риск категориясенә керә торган объектларга карата күчмә тикшерү үткәрелә.

Уртача куркыныч категориясенә керә торган объектларга карата документар тикшерү үткәрелә. Шактый зур куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы тикшерү чараларын үткәрү вакыты – 3 елга бер тапкыр.

Урта һәм уртача куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы тикшерү чараларын үткәрү вакыты – 4 елга бер тапкыр.

Түбән куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектына карата планлы контроль чаралары үткәрелми.

## 4.4. Планнан тыш тикшерү чаралары

4.4.1. Планнан тыш контроль чаралар документар һәм күчмә тикшерүләр, инспекция визиты, рейд тикшерүе, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшереп чыгу рәвешендә үткәрелә.

4.4.2. Планнан тыш тикшерү чарасын үткәрү турындагы карар мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларын исәпкә алып кабул ителә.

4.4.3. Планнан тыш тикшерү чаралары, үзара хезмәттәшлектән башка планнан тыш тикшерү чараларыннан тыш, түбәндәге нигезләр буенча үткәрелә:

1) контроль органында зыян (югалту) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы йә контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү сроклары җитү;

3) Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контроль үткәрелә торган затларга карата контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәсе;

---

[3]

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Контроль органы карарын үтәү срогы тәмамлану (248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда);

6) тикшерү программасында күрсәтелгән вакыйга булу, әгәр контроль төре турында федераль закон тарафыннан контроль чараларның тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелүе билгеләнсә.

4.4.4. Планнан тыш тикшерү чарасы прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына үткәрелергә мөмкин булса, әлеге чара мондый килештерүдән соң үткәрелә.

## 4.5. Документар тикшерү

4.5.1. Документар тикшерү дигәндә Контроль органының урнашу урынында үткәрелә торган контроль чара аңлашыла, аның предметы – контроль үткәрелә торган затларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләр генә, шулай ук аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм контроль органның мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле документлар.

4.5.2. Контроль органы карамагында булган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудыра яки бу белешмәләр контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, Контроль органы контроль үткәрелә торган зат адресына документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбен җибәрә.

Әлеге таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә контроль үткәрелә торган зат таләпләрдә күрсәтелгән документларны контроль органга җибәрергә тиеш.

4.5.3. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артырга тиеш түгел.

Күрсәтелгән срокка түбәндәге вакыттан соңгы чор кертелми:

1) таләптә күрсәтелгән документларны контроль органга тапшырганчы, Контроль органы тарафыннан контроль үткәрелә торган затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшырырга таләп җибәрү моменты;

2) контроль үткәрелә торган затка Контроль органы түбәндәгеләр турында мәгълүмат җибәргәннән соң чор:

контроль үткәрелә торган зат биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыкларны ачыклау турында;

тапшырылган документлардагы белешмәләрнең Контроль органында булган һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган документлардагы белешмәләргә туры килмәве турында һәм, күрсәтелгән аңлатмаларны контроль органга тапшырганчы, кирәкле аңлатмаларны язма рәвештә тапшырырга таләп.

4.5.4. Документар тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) документлар таләп итү;

2) язма аңлатмалар алу;

3) экспертиза.

4.5.5. Контроль чарасын үткәрү барышында инспектор контроль үткәрелә торган затка кирәкле һәм (яки) контроль үткәрелә торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәлешен бәяләү үткәрү өчен әһәмияткә ия булган документларны һәм (яки) аларның күчермәләрен, шул исәптән фотосъемка, аудио - һәм видеоязмалар, мәгълүмат базалары, мәгълүматлар банкы материалларын, шулай ук мәгълүмат йөртүчеләрне (носителей информации) тапшыру турында таләп куярга (җибәрергә) хокуклы.

Контроль үткәрелә торган зат әлеге таләпне алынганнан соң 10 эш көне эчендә таләп ителә торган документларны Контроль органга җибәрә яисә кичекмәстән язма рәвештә юллама белән инспекторга, сәбәпләрен һәм контроль үткәрелә торган затка таләп ителгән документларны тапшыру өчен кирәкле срокларын күрсәтеп, документларны билгеләнгән вакытта бирү мөмкинлеге булмавы турында хәбәр итә.

Фотосъемка, аудио - һәм видеоязмалар, мәгълүмат базалары, мәгълүматлар банкы материалларын, шулай ук мәгълүмат йөртүчеләрдән (носителей информации) файдалану мөмкинлеге документар тикшерү вакытына тикшерү чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны карау һәм эзләү хокуклары белән аларның логин һәм пароле рәвешендә бирелә.

4.5.6. Язма аңлатмалар инспектор тарафыннан контроль үткәрелә торган заттан яки аның вәкиленнән, шаһитлардан соратып алынырга мөмкин.

Күрсәтелгән затлар инспекторга тикшерү тәмамланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча ирекле формада язма аңлатмалар бирә.

Язма аңлатмалар ирекле формада язма документ төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Инспектор оешманың контроль үткәрелә торган вазыйфаи затлары яки хезмәткәрләре, гражданыны, аларның вәкилләре, шаһитләре сүзләре буенча кулдан язмача аңлатмалар төзергә хокуклы. Бу очракта күрсәтелгән затлар аңлатмалар белән танышалар, кирәк булганда текстны тулыландыралар, инспекторның аларның сүзләре буенча дөрес язуы турында билге ясыйлар һәм аны төзү датасын һәм урынын күрсәтеп, документка кул куялар.

4.5.7. Экспертиза Контроль органы кушуы буенча эксперт яки эксперт оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Экспертиза контроль үткәрелә торган затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында турыдан-туры контроль чарасын уздырганда, шулай ук эксперт яки эксперт оешмасы эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында да башкарылырга мөмкин.

Экспертизаны гамәлгә ашыру вакыты экспертиза төренә бәйле һәм Контроль органы белән эксперт яки эксперт оешмасы арасындагы килешү буенча һәр конкрет очракта аерым билгеләнә.

Экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.5.8. Актны рәсмиләштерү Контроль органның урнашкан урынында документар тикшерү узган көнне башкарыла.

4.5.9. Акт контроль үткәрелә торган затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә документар тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча Контроль органы тарафыннан җибәрелә.

4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килешмичә генә үткәрелә.

## 4.6. Күчмә (урынга барып) тикшерү

4.6.1. Күчмә тикшерү контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында алып барыла.

Күчмә тикшерү дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио- яки видеоэлемтә аша үткәрелергә мөмкин.

4.6.2. Күчмә тикшерү түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) Контроль органы карамагында булган яки ул соратып ала торган документларда һәм контроль үткәрелә торган затның аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгына һәм дөреслегенә ышанырга;

2) контроль үткәрелә торган затның һәм (яки) аның карамагындагы һәм (яки) ул файдалана торган контроль объектларының эшчәнлегенең, гамәлләренең (гамәл кылмавының) мәҗбүри таләпләргә туры килүен әлеге Нигезләмәнең 4.6.1 пунктында күрсәтелгән урынга чыкмыйча гына һәм контроль чараларының башка төре кысаларында каралган кирәкле контроль гамәлләр кылмыйча гына бәяләргә.

4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килешү буенча гына түбәндәге нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин:

1) контроль органында зыян (югалту) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы йә контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү сроклары җитү;

3) Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контроль үткәрелә торган затларга карата контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Контроль органы карарын үтәү срогы тәмамлану (248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда);

6) тикшерү программасында күрсәтелгән вакыйга булу, әгәр контроль төре турында федераль закон тарафыннан контроль чараларның тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелүе билгеләнсә.

7) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүнең турыдан-туры янавы турында белешмәләр алганда.

4.6.4. Контроль органы контроль үткәрелә торган затка күчмә тикшерү үткәрү турында, ул башланганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча, күчмә тикшерүне үткәрү турындагы карарның күчермәләрен контроль үткәрелә торган затка җибәрү юлы белән хәбәр итә.

4.6.5. Инспектор күчмә тикшерү уздырганда контроль үткәрелә торган затка (аның вәкиленә) хезмәт таныклыгын, күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарның күчермәсен күрсәтә, шулай ук контроль чараларның Бердәм реестрындагы хисап номерын хәбәр итә.

4.6.6. Күчмә тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмый.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата күчмә тикшерү уздыру барышында хезмәттәшлекнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән арта алмый.

4.6.7. Күчмә тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) карау (осмотр);

2) сораштыру;

3) документлар таләп итү;

4) язмача аңлатмалар алу;

5) экспертиза.

4.6.8. Карау инспектор тарафыннан контроль үткәрелә торган зат һәм (яки) аның вәкиле барында, мәҗбүри видеоязма кулланып башкарыла.

Карау (осмотр) нәтиҗәләре буенча карау беркетмәсе төзелә.

4.6.9. Сораштыру дигәндә мондый мәгълүмат булган контроль үткәрелә торган заттан яки аның вәкиленнән һәм башка затлардан инспектор тарафыннан контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләүне уздыру өчен әһәмиятле телдән мәгълүмат алудан гыйбарәт контроль гамәл аңлана.

Сораштыру нәтиҗәләре сораштырулар беркетмәсендә теркәлә, сораштыру беркетмәсенә сораштыру алынган зат тарафыннан үзе биргән белешмәләрнең дөреслеген раслый торган имза салына, шулай ук алынган белешмәләр контроль чара өчен зур әһәмияткә ия булган очракта контроль чара актында теркәлә.

4.6.10. Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү, сораштыру үткәргәндә, инспектор мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма, дәлилләрне теркәүнең башка алымнарын кулланырга хокуклы.

Фотога төшерү ярдәмендә мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының һәркайсын икедән дә ким булмаган фотога төшереп башкарыла.

Фотога төшерү һәм видеоязмаларны мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен куллану дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4.6.11. Контроль үткәрелә торган зат тарафыннан таләп ителә торган документларны, язмача аңлатмаларны тапшыру, экспертиза үткәрү әлеге Нигезләмәнең 4.5.5, 4.5.6 һәм 4.5.7 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.6.12. Күчмә тикшерү тәмамланганнан соң, инспектор күчмә тикшерү акты төзи.

Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма үткәрү турындагы мәгълүмат тикшерү актында чагылдырыла.

дистанцион хемәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио- яки видеоэлемтә аша күчмә тикшерү уздыру очрагында актны рәсмиләштергәндә, Нигезләмәнең әлеге пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән нигезләмә кулланылмый.

4.6.13. (Эшчәнлек алып бару) урынында контроль үткәрелә торган зат булмау сәбәпле, йә контроль үткәрелә торган затның эшчәнлеге фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, йә күчмә тикшерүне үткәрү яисә тәмамлау өчен мөмкинлекне булдырмаган контроль үткәрелә торган затның бүтән гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бәйле рәвештә күчмә тикшерүне үткәрү мөмкин булмаган очракта, инспектор, сәбәпләрен күрсәтеп, күчмә тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи һәм контроль үткәрелә торган затка, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә контроль чаралар үткәрү мөмкинлеге булмау турында хәбәр итә.

Бу очракта инспектор күчмә тикшерү уздыруның күрсәтелгән чоры кысаларында күчмә тикшерүне тәмалаганчыга кадәр контроль гамәлләр кылырга хокуклы.

4.6.14. Контроль үткәрелә торган затлар булган шәхси эшмәкәр, гражданин Контроль органына түбәндәге очракларда контроль чаралар үткәргәндә булу мөмкинлеге булмавы турында мәгълүмат бирергә хокуклы:

1) вакытлыча эшкә сәләтсезлек;

2) судларның, хокук саклау органнарының, хәрби комиссариатларның чакыруы (хәбәрнамәләр, повесткалар) буенча килү зарурилыгы;

3) Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә контроль чаралар үткәргәндә булу мөмкинлеген юкка чыгара торган чикләү чараларын сайлау;

4) хезмәт командировкасында булу.

Мәгълүмат килеп ирешкәндә, конҗроль чараларны үткәрү Контроль органы тарафыннан шәхси эшмәкәр, гражданинның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

## 4.7. Инспекция визиты, рейд тикшерүе (осмотр)

4.7.1. Инспекция визиты контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында алып барыла.

Инспекция визиты контроль үткәрелә торган затка һәм җитештерү объектының милекчесенә алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

Контроль үткәрелә торган затлар яки аларның вәкилләре инспекторның биналарга, корылмаларга, помещениеләргә тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

Бер эшчәнлек урынында яки бер җитештерү объектында (территориясендә) инспекция визитын үткәрү вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

4.7.2. Инспекция визиты барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:[4]

а) карау;

б) сораштыру;

в) язмача аңлатмалар алу;

г) мәҗбүри таләпләр нигезендә контроль үткәрелә торган затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) яисә контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиеш булган документларны таләп итү.

Инспекция визитын дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио- яки видеоэлемтә аша үткәрергә рөхсәт ителә.

4.7.3. Планнан тыш инспекция визиты бары тик прокуратура органнары белән килешү буенча гына түбәндәге нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин:

1) контроль органында зыян (югалту) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы йә контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү сроклары җитү;

3) Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контроль үткәрелә торган затларга карата контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Контроль органы карарын үтәү срогы тәмамлану (248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда);

6) тикшерү программасында күрсәтелгән вакыйга булу, әгәр контроль төре турында федераль закон тарафыннан контроль чараларның тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелүе билгеләнсә.

7) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүнең турыдан-туры янавы турында белешмәләр алганда.

4.7.4. Рейд тикшерүе җитештерү объектына ия булучы, аннан файдаланучы яки идарә итүче контроль үткәрелә торган затларга карата ничәү булсалар да үткәрелә.

---

4

Рейд тикшерүе вакытында бер контроль үткәрелә торган зат белән үзара хезмәттәшлек итү срогы бер эш көненнән дә арта алмый.

4.7.5. Күчмә тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

а) карау;

б) сораштыру;

в) язмача аңлатмалар алу;

г) документлар таләп итү;

д) экспертиза.

4.7.6. Җитештерү объектларына ия, алардан файдалана яки идарә итә торган контроль үткәрелә торган затлар рейд тикшерүе барышында инспекторларның рейд тикшерүе үткәрү турында карарда күрсәтелгән җитештерү объектларына, шулай ук барлык помещениеләргә (торак помещениеләрдән тыш) тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

4.7.7. Рейд барышында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, инспектор рейд тикшерүе үткән урында, мәҗбүри таләпләрне бозган һәр контроль үткәрелә торган затка карата контроль чарасының актын төзи.

4.7.8. Рейд тикшерүе бары тик прокуратура органнары белән килештереп, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә үткәрелү очракларыннан тыш үткәрелергә мөмкин.

4.7.9. Әлеге Нигезләмәнең 4.7.2 һәм 4.7.5 пунктларында каралган контроль гамәлләр әлеге Нигезләмәнең 4.5.5-4.5.7, 4.6.8-4.6.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.8. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы)

4.8.1. Контроль органы, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә (куркынычсызлык мониторингы), Контроль органында булган контроль объектлары турында мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында керә торган, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны, шулай ук дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, «Интернет» челтәреннән алынган мәгълүматларны, һәркем өчен ачык булган мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимында эшләүче техник чараларын кулланып алынган мәгълүматларны җыю, анализлау уздыра.

4.8.2. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү яисә зыян (югалту) китерү куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрнең бозылуы, мәҗбүри таләпләрне бозуның әзерләнүе яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, Контроль органы тарафыннан планнан тыш тикшерү чарасын үткәрү турында түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү яисә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең дөреслеге расланган очракта яисә контроль үткәрелә торган зат эшчәнлегенең аларга туры килү яисә алардан тайпылу, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының расланган индикаторларына ярашлы рәвештә, контроль чарасын үткәрү өчен нигез булып тора торган параметрларын билгеләгәндә – контроль чарасын үткәрү турында дәлилләнгән күрсәтмә (представление);

закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү яисә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең дөреслеге раслау булмаган очракта яисә контроль үткәрелә торган зат эшчәнлегенең аларга туры килү яисә алардан тайпылу, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының расланган индикаторларына ярашлы рәвештә, контроль чарасын үткәрү өчен нигез булып тора торган параметрларны билгеләп булмаганда – мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү юллау турында дәлилләнгән күрсәтмә (представление);

гражданинның шәхесен, оешма вәкиленең вәкаләтләрен раслау мөмкин булмаса, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү яисә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең дөрес булмавын ачыклау - тикшерү чарасын үткәрү өчен нигез булмау турында дәлилләнгән күрсәтмә (представление).

2) кисәтү игълан итү турында карар;

3) контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә беркетелгән карар

## 4.9. Күчмә тикшереп чыгу (обследование)

4.9.1. Күчмә тикшереп чыгу контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен бәяләү максатларында үткәрелә.

4.9.2. Күчмә тикшереп чыгу оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында, гражданинның эшчәнлек алып бару урынында, контроль үткәрелә торган объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контроль үткәрелә торган зат белән хезмәттәшлек итү рөхсәт ителми.

һәркем керерлек булган (чикләнмәгән даирә затларына керү өчен ачык булган) җитештерү объектларында күчмә тикшерү (обследование) барышында карап чыгу (осмотр) үткәрергә мөмкин.

4.9.3. Күчмә тикшереп чыгу контроль үткәрелә торган затка хәбәр итми генә үткәрелә.

Бер объектны (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектны) күчмә тикшереп чыгу уздыру вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

4.9.4. Күчмә тикшереп чыгу үткәрү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында каралган карарлар кабул ителә алмый.

## 5. Контроль органы җитәкчесе урынбасарының һәм инспекторларның карарларына шикаять белдерү

5.1. Контроль органы җитәкчесе урынбасары һәм инспекторларның карарларына суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Тикшерү органы җитәкчесе урынбасары һәм инспекторларның карарларына шикаятьләрне судка кадәр бирү тәртибе кулланылмый.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроле турынд Нигезләмәсенә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары исемлеге**

1. Җитәкче урынбасары (төзелеш буенча);
2. Инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроле турынд Нигезләмәсенә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркыныч (риск) категорияләренә кертү критерийлары**

| т/б | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспорты һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә муниципаль контроль объектлары | Риск категориясе |
|---|---|---|
| 1 | Юридик зат яисә шәхси эшмәкәр эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә соңгы өч ел эчендә законлы көченә кергән, автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында эшчәнлек алып барганда контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан башкарылырга (үтәлергә) тиешле мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле административ хокук бозу өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында карар булганда – юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр | Шактый зур куркыныч (значительный риск); |
| 2 | Юридик зат яисә шәхси эшмәкәр эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә соңгы өч ел эчендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында эшчәнлек алып барганда контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан үтәлергә (үтәлергә) тиешле мәҗбүри таләпләрне үтәмәү факты буенча бирелгән карарда билгеләнгән срокта үтәлмәгән булганда – юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр | Урта куркыныч (средний риск) |
| 3 | Юридик зат яисә шәхси эшмәкәр эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә соңгы биш ел эчендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында эшчәнлек алып барганда контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан үтәлергә (үтәлергә) тиешле мәҗбүри таләпләрне үтәмәү фактын бозу буенча ачыкланганпланлы яисә планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча булганда – юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр | Уртача куркыныч (умеренный риск) |
| 4 | юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркыныч (риск) категорияләренә кертүнең әлеге Критерийларының 1, 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән шартлар булмаганда, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар | Түбән куркыныч (низкий риск) |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

| **Индикатор исеме** | **Сайланган параметр өчен нормаль торышы (бәяләү критерийлары), үлчәү берәмлеге (булганда)** | **Риск индикаторы күрсәткече** |
|---|---|---|
| 1 индикатор исеме | 5-10, шт. | < 5 шт. или<br>> 10 шт. |
| 2 индикатор исеме | юк | әйе |
| 3 индикатор исеме | ... № ... Федераль закон нигезендә билгеләнә | нормаль параметрларның 10 % тан артык кимүе яки артуы |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр.**

1.Төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан әһәмияте:

Мәҗбүри таләпләрне бозулар арасыннан бетерелгән тәртип бозулар өлеше – 70%.

Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү өлеше – 100%.

Контроль чаралар үткәргәндә тикшерү органы һәм (яки) аның вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләрнең өлеше – 0%.

Тикшерү чараларының гамәлдән чыгарылган нәтиҗәләре өлеше – 0%.

Нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланган, ләкин тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән контроль чаралары өлеше – 5%.

Контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында чыгарылган суд карарларының өлеше – 95%.

2. Индикатив күрсәткечләр:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнә:

уздырылган планлы тикшерү чаралары саны;

уздырылган планнан тыш тикшерү чаралары саны;

контроль чарасы актына карата кергән каршылыклар (возражение) саны;

бетерелгән мәҗбүри таләпләрне бозулар саны.